# Авыл фельдшеры

*Бу көннәрдә медицина хезмәткәрләре һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр. Әлеге дата хезмәт һәм медицина ветераны Лотфиева Шәмсия Вагыйз кызы өчен дә якын.*

1936 елның 22 ноябрендә Минзәлә районы Калмыя авылында туган кыз язмышын ни өчен медицина белән бәйли соң?

-1954 елда урта мәктәпне тәмамлагач, документларымны Минзәлә медицина училищесына тапшырдым, - ди Шәмсия Вагыйзовна. – Әтием сугышта үлде, аннан соңгы авыр елларда ике туганым гүр иясе булдылар. Кешеләргә ярдәм итү теләге шул вакытта тугандыр, мөгаен.

Дипломлы фельдшерны юллама буенча Менделеев районыны җибәрәләр. Ш.Лотфиева беренче хезмәт чыныгуын Тойма авылында ала. Яшь белгеч эштә үҗәтлеге, җәмәгать тормышында актив катнашуы белән аерылып тора. Бер мәлне, район үзәгенә җыелышка килгәч. Ул булачак тормыш иптәше Мулланурны очрата. Белеме буенча педагог егет Шәмсияне мәңгелек яр итеп Бәзәкәгә алып кайта.

Ул вакытта “Кама” колхозы составына Татар һәм Мари Тәкәшләре, Сәйтәк, Ык Тамагы авыллары керә. Ә Бәзәкә халкы – 1500 кеше. Шәмсия Вагыйзовна өчен тынгысыз эш көннәре башлана. Яшь медик тиз арада авыл халкында ихтирам казана. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында күрсәтелгән сыйфатлы ярдәм, табибәнең йомшак куллары , юату сүзләре авыруның хәлен җиңеләйтүдә зур роль уйный.

Бәзәкәдә ун ел чамасы бала тудыру йорты да эшли. Ул чорларда елга 70 әр нәни аваз сала. Ш.Лотфиева – акушерның алыштыргысыз булышчысы.

-Бервакыт бала тудыручы анага өй шартларында ярдәм күрсәтергә туры килде,- дип искә ала әңгәмәдәшем. –Бала тудыру йортына барып җитәргә өлгермибез. Аллага тапшырдым да, тәвәккәлләдем. Бәхетле ананың өч игезәге туды.

Энергиясе ташып торган фельдшер бар эшкә дә өлгерә. Мәктәптә, балалар бакчасында, клубта. Ферманың кызыл почмагында санитария һәм гигиена темасына лекцияләр укый, агитацияләр алып бара. Авыл Советы депутаты итеп сайлангач та сынатмый.

Аның фидакарь хезмәте ТАССРның сәламәтлек саклау министрыгы, район Советының Мактау грамоталары белән билгеләп кителә, “I-дәрәҗә фельдшер” дигән исемгә лаек була.

Медицинага 40 ел гомерен багышлаган Шәмсия Вагыйзовна бүген лаеклы ялда.Ләкин ул кул кушырып утырырга яратмый. Бакчада эшли, яраткан

оныклары белән мәш килә. Шәмсия апа тормыш иптәше Мулланур абый белән ике кыз, бер ул үстерә. Балалары югары белемле. Рузилә әнисе һөнәрен сайлаган, Киров шәһәрендә теш табибы булып хезмәт куя. Резедә белән Дамир – шәхси эшмәкәрләр. Ни кызганыч, Мулланур ага гына аларның уңышларына сөенә, инде оныкларының да җәмгыятькә файдалы кешеләр булып үсеп җитүен , кечкенә оныкчыгы тууын күрә алмады. Аның вафатына 10 ел.

Ш.Лотфиева әле дә медицина яңалыклары белән кызыксына, махсус әдәбият укырга ярата, сәламәт яшәү рәвеше алып бара. Һөнәри бәйрәмендә аңа иминлек, озын гомер телибез.

Р.Мирзаянова .“Менделеев яңалыклары”, 2007 ел, 15 июнь.




Курорт
Июнь 1977г.







Дамир, Мулланур, Шәмсия, Рузилә, Резеда

Оныклар: Тимур, Руслан, Ләйсән, Ренат, Рөстәм.



Оныклар:

Алмаз, Тимур, Рөстәм, Ләйсән, Илназ, Руслан, Ренат



Сулдан уңга аста:

Ләйсән, Резеда, Тимур, Алмаз, Рөстәм, Ренат, Руслан

Дамир, Рузилә, Мулланур, Ландыш, Ильназ, Шәмсия, Фирдәвес





# УДОСТОВЕРЕНИЕ

Лутфиева
Шамсия
Вагизовна

за долголетний добросовестный труд от имени Президиума Верховного Совета СССР Указом Президиума Верховного Совета Татарской АССР от 24 марта 1982 г.

награжден медалью

„ВЕТЕРАН ТРУДА“

Секретарь Президиума Верховного Совета Татарской АССР

М. П.

« ..... » ..................... 19...... г.

Президиум Верховного Совета Татарской АССР



„ЗА ДОБЛЕСТНЫЙ ТРУД. В ОЗНАМЕНОВАНИЕ 100-ЛЕТИЯ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ ВЛАДИМИРА ИЛЬИЧА ЛЕНИНА“

# УДОСТОВЕРЕНИЕ

Лутфиева
Шамсия
Вагизовна

ОТ ИМЕНИ ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР
НАГРАЖДЕН ЮБИЛЕЙНОЙ МЕДАЛЬЮ

„ЗА ДОБЛЕСТНЫЙ ТРУД. В ОЗНАМЕНОВАНИЕ 100-ЛЕТИЯ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ ВЛАДИМИРА ИЛЬИЧА ЛЕНИНА“

Секретарь исполкома
Елабужского
районного
Совета депутатов трудящихся

М. П. « 8 » апреля 1970 года.

Медицинада озак еллар фидакарь хезмәте, кече ватаны Бәзәкә авылына һәм аның кешеләренә тугрылыгы, шәфкатьлелеге, мәрхәмәтле йөрәге һәм бары тик игелек кылырга омтылуы өчен

бүләкләнә

# «Алтын йөрәкле кеше»

**Лотфиева**
**Шәмсия Вагыйзовна,**

сәламәтлек саклау һәм хезмәт ветераны

Комиссия рәисе
Әгъзалары

Р.З.Насифуллина
авыл Советы депутатлары